СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 2-16 «12» май 2017 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 елның 12 ноябрендәге 7-12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Инвестицияләр, инновацион технологияләр җәлеп итү, шулай ук предприятиеләргә һәм оешмаларга, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү, җитештерүне, сәнәгатьне үстерү, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә эш урыннарын арттыру максатларында, 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы “Конкуренцияне яклау турында” гы Федераль законның 19 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 елның 12 ноябрендәге 7-12 номерлы карары белән расланган “2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясенә” түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. “"Вятка" сәнәгать паркын үстерү” 4.3.7. статьяда 3 пункттан соң беренче абзацтан соң түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац өстәргә:

«Преференцияләр «Вятка» сәнәгать паркы территориясендә җитештерү эшчәнлеген җир кишәрлеген арендалау килешүе буенча 99 процентка түләүдән азат итү юлы белән җир кишәрлекләрен арендага алу өчен айлык түләүләр кертү буенча ташламалар рәвешендә гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә.».

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының бюджет, икътисади сәясәт һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов